**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» март, 2020 ел № 351

Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019 елның 18 июнендә
кабул ителгән 932 нче номерлы төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык
бүлегенә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларына үзгәрешләр
кертү турында (04.10.2009 ел, №1550, 28.11.2019 ел,
№1907, №11.12.2019 ел, №1981, 17.12.2009 ел,
№ 1999 үзгәрешләр белән)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон нормаларына һәм РФ Хөкүмәтенең «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2006 елның 9 июнендәге 363 номерлы карарына туры китерү максатларында административ регламентларга үзгәрешләр кертү зарурилыгы белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 18 июнендәге 932 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 22 номерлы кушымтаның 1.5 пунктының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2 Мәгълүмат системасындагы белешмәләрне бирү дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, мәгълүмат системасы белешмәләрен алу белән кызыксынган физик яисә юридик зат (алга таба - кызыксынучы затлар) соравы нигезендә гамәлгә ашырыла».

1.2 5 пунктның 10 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«10) мөрәҗәгать итүченең дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда, яисә әлеге Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, документларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларның

яисә белешмәләрнең таләбе. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күп функцияле үзәккә Федераль законның 16 статьясындагы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү функциясе йөкләнгән булса мөмкин».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http:/www.pestreci.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге: Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Район башкарма комитеты җитәкчесе — А. В. Хәбибуллин